**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

27.04.2020 Казан ш. № 55од

Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратларында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре белән төзелә торган хезмәт контрактлары турында

«Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 4 өлешнең 5 пункты, «Россия Федерациясе җәмәгать судьялары турында» 1998 елның 17 декабрендәге Федераль законның 7 һәм 9 статьялары, «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» 1999 елның 17 ноябрендәге Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 9 статьялары нигезендә, боерам:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратларында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына билгеләнүче гражданнар белән тиешле суд участогының җәмәгать судьясы белән килешү буенча аның вәкаләтләре вакытына вакытлы хезмәт контрактлары төзелә дип билгеләргә.
2. Әлеге боерыкның 1 пункты әлеге боерык үз көченә кергәнче булган хокук мөнәсәбәтләренә, шулай ук Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратларындагы «Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясының 2 өлешендә, 31 статьясының 1 өлешендә каралган очракларда Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратларында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең башка вазыйфаларына билгеләнгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә кагылмый, әгәр дә әлеге боерыкны бастырып чыгару вакытына алар белән билгеле булмаган вакытка хезмәт контрактлары төзелгән булса.
3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненән үз көченә керә дип билгеләргә.
4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз карамагымда калдырам.

Министр Р.И. Заһидуллин